ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 1991 от 23.12.2025

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2024 елның 27 декабрендәге 2220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга Санитар - эпидемиологик таләпләр» СанПиНның 2.3/2.4.3590-20 номерлы балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү учреждениеләрендә укучыларны балансланган кайнар аш белән тәэмин итү нормаларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2024 елның 27 декабрендәге 2220 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.4. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«2.4. Гомуми белем бирү муниципаль оешмаларында түбәндәгеләрне билгеләргә:

- туклануга компенсация түләүләре күләмен -10 сум 70 тиен итеп;
- шәһәр мәктәпләренең 1-4 сыйныф балалары өчен бер укучыга көненә уртача кайнар ризык бәясе күләмен - 77 сум 76 тиен (федераль акчалар исәбеннән), 5-11 сыйныф балалары өчен - 83 сум 20 тиен итеп (10 сум 70 тиен җирле бюджеттан, 72 сум 50 тиен ата-аналар түләве исәбеннән);
- авыл мәктәпләренең 1-4 сыйныф балалары өчен бер укучыга көненә уртача кайнар ризык бәясе күләмен - 77 сум 76 тиен (федераль акчалар исәбеннән), 5-11 сыйныф балалары өчен - 80 сум 00 тиен итеп (10 сум 70 тиен җирле бюджеттан түләнә, 69 сум 30 тиен ата-аналар түләве исәбеннән;

- озайтылган көн төркемнәрендә укучыларның уртача туклану бәясе күләмен - 66 сум 70 тиен итеп ата-аналар исәбеннән. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы һәм Росгвардия бүлеге хезмәткәрләре балалары өчен 50% күләмендә ташламалар бирелми. Туклану бәясе шәһәр, шулай ук авыл мәктәпләре укучылары өчен дә бертөрле;

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «3 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең кадет сыйныфлары өчен көненә бер укучыга уртача туклану бәясе күләмен - 160 сум 60 тиен итеп (10 сум 70 тиен җирле бюджеттан түләнә, 149 сум 90 тиен ата-аналар түләве исәбеннән), аз керемле һәм күпбалалы гаиләләрдәге балалар өчен - 83 сум 20 тиен муниципалитет һәм 66 сум 70 тиен ата-аналар түләве исәбеннән;

- шәһәр һәм авыл мәктәпләренең 1-4 сыйныф балалары (сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар, инвалидлар, шулай ук хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән укучылар) өчен -144 сум 46 тиен итеп;

-5-11 сыйныф балалары (сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балалар, инвалидлар, шулай ук хәрби хезмәткәрләр гаиләләреннән укучылар) өчен бер укучыга көнгә ике тапкыр кайнар аш белән туклануның уртача бәясе күләмен: шәһәр мәктәпләрендә - 149 сум 90 тиен һәм авыл мәктәпләрендә - 146 сум 70 тиен итеп;

- шәһәр мәктәпләрендә шикәр диабеты белән авыручы бер укучы баланы индивидуаль тукландыруның уртача бәясе күләмен: 1-4 сыйныфллар өчен - 77 сум 76 тиен, 5-11 сыйныфлар өчен - 83 сум 20 тиен итеп;

- авыл мәктәпләрендә шикәр диабеты белән авыручы бер укучы баланы индивидуаль тукландыруның уртача бәясе күләмен: 1-4 сыйныфллар өчен - 77 сум 76 тиен, 5-11 сыйныфлар өчен - 80 сум 00 тиен итеп;

- Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Инженер-технология лицее» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең спорт сыйныфлары өчен көненә бер укучыга уртача туклану бәясе күләмен – 322 сум итеп (80 сум 50 тиен җирле бюджеттан түләнә, 80 сум 50 тиен йөзү федерациясе тарафыннан түләнә, 161 сум ата-аналар түләве исәбеннән).»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.А. Томилин